Республика Татарстан
Альметьевское сельское поселение Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

19 июнь 2018 ел № 7

«2018-2022 елларда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә сөтчелек юнәлешендә терлекчелекне үстерү» муниципаль программасы хакында

«Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары нигезендә, Сарман муниципаль районында авыл хуҗалыгы продукциясенең конкуренциягә сәләтлелеген арттыру һәм терлекчелекне үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында карар бирәм:

1. «2018-2022 елларда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә сөтчелек юнәлешендә терлекчелекне үстерү» муниципаль программасын (алга таба-Программа) расларга.

2. Программаны башкаручыларга Программаны үз вакытында һәм тулысынча үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз остемә алам.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Д. Э. Газизов